## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеген Ары торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

"08" ноябрь 2020 ел. №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Күлле-Киме авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №109 карары нигезендә, 2020 елның 08 ноябрендә «Сез 2021 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Ары авылында җирлек территориясен чистарту һәм төзекләндерү
- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм яктырткычлар алу
- вак таш сатып алу һәм транспорт өчен түләү.

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 204 (ике йөздә дүрт) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 129 (йөз егерме тугыз) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 129 (йөз егерме тугыз) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

"Сез 2021 елда Күлле-Киме авыл җирлеге Ары торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган яшәүчегә, 500 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме: "Ары авылында җирлек территориясен чистарту һәм төзекләндерү

- урамнарны яктырту хезмәте күрсәтү һәм яктырткычлар алу
- вак таш сатып алу һәм транспорт өчен түләү" мәсьәләсен кабул итәргә.

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлеге Ары авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Күлле-Киме авыл җирлеге башлыгы Гәрәев Х.Х.